**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2

**СОВЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422725,Республика Татарстан,Высокогорский район, с.Большой Битаман, ул. Московская, 2

тел./факс 8(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**09 октябрь 2020 е.** **№ 5**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге җирле үзидарә органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 декабрендәге 157 номерлы карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә, Олы Битаман авыл җирлеге Уставына таянып, Олы Битаман авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирләүгә тарифлар билгеләү һәм җирләү эше өлкәсендә җирле үзидарә вәкаләтле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшырырга;
2. Әлеге карарны карау өчен Биектау муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә (Әмминов Алмаз Әхәт улы) Биектау муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә артмаган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзү буенча як булырга;
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы А.Ә.Әминов